**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2016 елның «31» мартыннан № 123

**«ЭкоЯз» конкурсын игълан итү турында»**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы күрсәтмәләре нигезендә:

1. 2016 елның 1 апреленнән 15 маена кадәр төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгы кысаларында Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «ЭкоЯз» конкурсын игълан итәргә.

2. Конкурс турындагы Нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

3. «ЭкоЯз 2022» конкурсына йомгак ясау буенча комиссия составын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге боерыкны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «31» мартыннан
123 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«ЭкоЯз» конкурсы турында**
**нигезләмә**

**Конкурсны оештыручылар:**
Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты.

**Уздыру вакыты**
2016 елның 1 апреленнән 20 маена кадәр

**Конкурсның максатлары:**
- Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитенә экологик культураны һәм сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру;
- халыкның хезмәт һәм экология культурасын тәрбияләү эшендә традицияләрне торгызу;
- яшәү урыннарында чисталык өчен балаларның социаль җаваплылыгын тәрбияләү;
- әйләнә-тирә мохитне саклау эшендә гражданнар, оешмалар һәм дәүләт хакимияте органнары инициативасын берләштерү.

**Конкурсның бурычлары:**
- халыкның, мәгариф оешмаларының һәм массакүләм мәгълүмат чараларының туган як табигатен саклау мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлеген активлаштыру;
- каты көнкүреш калдыкларын аерым җыю системасын популярлаштыру;
- әйләнә-тирә мохитне саклау һәм чистарту, табигать ресурсларыннан һәм калдыклардан нәтиҗәле файдалану, энергияне сак тоту зарурлыгы турында халыкның мәгълүматлылыгын арттыру.

**Номинацияләр:**

«Эко мәктәп»

«Эко гаилә»

«Эко оешма»

**Акция кысаларында тәкъдим ителә торган чаралар:**

- территорияләрне төзекләндерү һәм санитар чистарту;
- флэшмоблар;
- кече архитектура формаларын төзү;
- агачлар утырту;
- сыерчык оялары ясау;
- экологик дәресләр үткәрү;
- көнкүреш калдыкларын бүлеп җыю;
- җырлар һәм шигырьләр иҗат итү;
- Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитенә сакчыл мөнәсәбәткә юнәлтелгән экологик акцияләр һәм башка чаралар уздыру;
- социаль челтәрләргә урнаштырылган #экояз хештегы белән шимбә өмәсеннән иң креатив фотография;
- социаль челтәрләргә урнаштырылган #экояз хештегы белән шимбә өмәсеннән иң креатив видео.

**Конкурста катнашучылар:**

Конкурста Яңа Чишмә муниципаль районының барлык халкы, мәгариф оешмалары катнаша ала. Яшь буенча чикләүләр юк.

**Гаризаларны бәяләү критерийлары:**

1. Чаралар үткәрүнең актуальлеге (яңалыклар, максатларга һәм бурычларга туры килү, нәтиҗә, масштаб);
2. Катнашучылар саны, активлык, инициативалылык;
3. Җәмәгатьчелекне җәлеп итү.
4. Чараны мәгълүмати яктырту.

**Конкурска гаризаларны рәсмиләштерү:**

Конкурста катнашучыларның отчет материаллары Яңа Чишмә муниципаль районының административ комиссиясенә электрон рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрелә: Adm.Komissiya@tatar.ru

Җаваплы затка гариза белән бергә раслаучы материаллар (башкарылган чара турында ирекле формада отчет, фотолар, массакүләм мәгълүмат чараларындагы язмаларга сылтамалар) җибәрелә.

**Нәтиҗәләр ясау**

Конкурска йомгакны жюри ясый. Конкурста җиңүчеләр (һәр номинациядә 1 җиңүче) дипломнар һәм призлар алачак.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
эшләре белән идарә итүче

М.Д.Губкина

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «31» мартыннан
123 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«ЭкоЯз» конкурсына йомгак ясау буенча комиссия составы**

**Комиссия рәисе:**

| | | |
|---|---|---|
| Фасахов Р.Р. | - | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

**Комиссия секретаре:**

| | | |
|---|---|---|
| Астраханцева Н.В. | - | Яңа Чишмә муниципаль районы административ комиссиясенең җаваплы секретаре |

**Комиссия әгъзалары:**

| | | |
|---|---|---|
| Габетдинов Р.Х. | - | - Яң а Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары |
| Еронтьев А.Л. | - | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы |
| Исхакова Л.К. | - | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары |
| Семеняк В.Н. | - | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
эшләре белән идарә итүче М.Д. Губкина